КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 август г.Казань № 699

Татарстан Республикасы территориясендә бердәм номер белән тәүлек буе эшли торган яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеген тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 10 пункты, 7 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 елның 11 июлендәге 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3 пунктындагы 8 пунктчасы нигезендә, авыр тормыш хәлендә калган яшь гражданнарга ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә бердәм номер белән тәүлек буе эшли торган яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеген тәэмин итү турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәкләренең муниципаль йөкләмәсенә яшьләр ышаныч телефонынннан файдалану юлы белән яшьләргә консультация ярдәме күрсәтүне кертүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеге турында мәгълүмат биреп торуны гамәлгә ашыруны.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 26 август, 699 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә бердәм номер белән тәүлек буе эшли торган яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеген тәэмин итү турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә бердәм номер белән тәүлек буе эшли торган яшьләр ышаныч телефоны (алга таба – яшьләр ышаныч телефоны) эшчәнлеген җайга сала.

1.2. Яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеген координацияләү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

II. Яшьләр ышаныч телефоны эшенең максаты һәм юнәлеше

2.1. Яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеге яшьләр һәм аларның мәнфәгатьләрен яклаучы затлар мөрәҗәгать иткәндә кризислы хәлдә булганда телефоннан аноним мәгълүмат һәм ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү максатларында гамәлгә ашырыла.

2.2. Яшьләр ышаныч телефонының эш юнәлешләре:

кризислы хәлдә булганда, шул исәптән суицид куркынычы янаган очракларда, яшьләргә һәм аларның мәнфәгатьләрен яклаучы затларга ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү;

яшьләрнең үсеш һәм яшь үзенчәлекләре, балалар белән ата-ана мөнәсәбәтләре, ир белән хатын һәм гаилә мөнәсәбәтләрен формалаштыру, шәхесара мөнәсәбәтләр булдыру, яшьләрнең социаль-психологик үсешендә тәртип тайпылышларын коррекцияләү, яшьләрнең психик сәламәтлеген саклау, сәламәт яшәү рәвеше алып бару, яшьләр мохите арасында социаль тискәре күренешләрне профилактикалау мәсьәләләре буенча дистанцион психологик консультация бирү (телефоннан);

Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеген популярлаштыруга, авыр тормыш хәлләрендә булганда яшьләрнең шалтыратуларына мотивация ясауга, яшьләрнең һәм аның якыннарының психологик культурасын арттыруга, аддиктив һәм суицидаль тәртипне, шулай ук башка социаль тискәре күренешләрне профилактикалауга юнәлдерелгән мәгълүмати-агарту эшчәнлеге;

яшьләр ышаныч телефоны белгечләренең һөнәри компетенцияләрен арттыруга, һөнәри осталыкларын камилләштерүгә, инновацион эш тәҗрибәсен гомумиләштерүгә һәм таратуга (яшьләр хокукларын яклау мәсьәләләре буенча профилактика программалары, проектлар, семинарлар, «түгәрәк өстәлләр» утырышлары, мәгълүмат

материаллары әзерләүгә, тикшеренү материалларын эшкәртүгә), яшьләр ышаныч телефоны линияләрендә эшләүче белгечләрнең эмоциональ янып бетүен профилактикалауга юнәлдерелгән методик эшчәнлек.

## III. Яшьләр ышаныч телефоны эшен оештыру һәм аның эш тәртибе

3.1. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр ышаныч телефоны эшләвен тәэмин итү өчен яшьләр сәясәте оешмаларын яисә аларның структур бүлекчәләрен бердәм республика номерына тоташтыру гамәлгә ашырыла.

3.2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

яшьләр ышаныч телефоны аша күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын контрольдә тотуны;

яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеген статистик исәбен алып баруны;

яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеген тәэмин итү буенча оештыру һәм методик эшләрне;

Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеген популярлаштыруга юнәлдерелгән реклама-мәгълүмат кампаниясен оештыруны;

федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының рәсми сораулары буенча яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеге турында мәгълүмат әзерләүне;

яшьләр ышаныч телефоны линиясендә эшләүче белгечләрнең ведомство супервизиясен оештыруны (балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү буенча муниципаль үзәкләрнең рәсми соравы буенча).

3.3. Яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеге түбәндәгеләрне тәэмин итә:

яшьләр һәм аларның мәнфәгатьләрен яклаучы затлар мөрәҗәгать иткәндә кризислы хәлдә булганда телефоннан аноним мәгълүмат һәм ашыгыч психологик ярдәм күрсәтүне;

яшьләр ышаныч телефоны линиясендә эшләүче белгечләрнең эш графигын булдыруны;

яшьләр ышаныч телефонына шалтыратуларны исәпкә алуны алып баруны;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, әлеге Нигезләмәгә кушымтада бирелгән форма буенча яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеге турында хисап бирүне;

яшьләр ышаныч телефоны эше кысаларында керә торган мәгълүматның конфиденциальлеген, шулай ук яшьләр ышаныч телефонына мөрәҗәгать итүче затларның һәм яшьләр ышаныч телефонында эшләүче белгечләрнең (педагог-психологларның) шәхси мәгълүматын саклауны тәэмин итү.

3.4. Яшьләр ышаныч телефоны эше яшьләр сәясәте, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, мәгариф һәм медицина оешмалары, эчке эшләр органнары, шулай ук, яшьләрнең хокукларын яклау таләпләрен исәпкә алып, кызыксынучы башка оешмалар белән берлектә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә бердәм номер белән тәүлек буе эшли торган яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеген тәэмин итү турындагы нигезләмәгә кушымта

Форма

## Татарстан Республикасы территориясендә бердәм номер белән тәүлек буе эшли торган яшьләр ышаныч телефоны эшчәнлеге турында хисап

| Коды | Мөрәҗәгатьләр кодификаторы | Татарстан Республикасы территориясендә бердәм номер белән тәүлек буе эшли торган яшьләр ышаныч телефонына мөрәҗәгатьләр килде | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | ир-атлар | хатын-кызлар | мөрәҗәгать итүчеләрнең яшь категориясе | | | | | | | | | | ата-аналардан, балигъ булмаганнарның законлы вәкилләреннән мөрәҗәгатьләр керде | |
| | | | | | 14 яшькә кадәр | | 14 яшьтән 17 яшькә кадәр | | 18 яшьтән 24 яшькә кадәр | | 25 яшьтән 35 яшькә кадәр | | 35+ (башка гражданнар) | | | |
| | | | | | ир-атлар | хатын-кызлар | ир-атлар | хатын-кызлар | ир-атлар | хатын-кызлар | ир-атлар | хатын-кызлар | ир-атлар | хатын-кызлар | ир-атлар | хатын-кызлар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| 1. | Суицид | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | Суицидаль идеация (идеяләр, фикерләр, планлаштыру) | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2. | Озак депрессия | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.3. | Агымдагы суицид | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.4. | Кабул ителгән карар | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.5. | Суицидаль омтылыштан соң хәл | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.6. | Үз-үзеңә зыян салу (селфхарм) | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.7. | Якын кешенең суициды | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.8. | Суицидаль рецидив | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2. | Гаиләдәге проблемалар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. | Балаларның ата-аналар белән булган низагы турында мөрәҗәгатьләре | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.2. | Үз балалары белән үзара мөнәсәбәтләрдә кыенлыклар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.3. | Башка якын туганнар (абый-энеләр, апа-сеңелләр, әбиләр, бабайлар) белән низаглар турында мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.4. | Баланы тәрбияләү, үстерү һәм гигиена буенча ата-аналарның проблемалары | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.5. | Балаларның ата-аналары аерылышуы белән бәйле кичерешләре | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.6. | Уллыкка / кызлыкка алу; опека, попечительлек; тәрбиягә бала алучы гаилә буенча мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.7. | Баланың яңа гаиләгә адаптациясе | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.8. | Балаларның ата-аналары психоактив матдәләр куллану буенча мөрәҗәгате | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.9. | Гаилә әгъзаларының берсе үлүгә бәйле рәвештә борчылулар. Ятимлек | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.10. | Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрдә кыенлыклар. Ир белән хатын хыянәте | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.11. | Гаилә низагы | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.12. | Аерылышу. Ире (хатыны) белән булачак аерылышу | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.13. | Граждан никахында яшәүгә бәйле гаилә проблемалары | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3. | Бала хокукларын яклауны таләп итә торган мөрәҗәгатьләр. Балаларның хокукларын яклау һәм кеше хокукларын яклау буенча юридик сораулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. | Яшьүсмергә карата көч куллану (физик, психологик, сексуаль) | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.2. | Гаилә эчендәге инцестлы мөнәсәбәтләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.3. | Баланың ихтыяҗларын санга сукмау | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.4. | Белем бирү учреждениеләрендә физик һәм / яки психологик көчләүдән соң имгәнү: | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.4.1. | укучылар ягыннан | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.4.2. | укытучылар ягыннан | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.5. | Сәламәтлекләренең мөмкинлек-ләре чикләнгән яшүсмерләрнең хокукларын чикләү | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.6. | Яшүсмернең белем алуга, медицина хезмәте күрсәтүгә хокукларын чикләү | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.7. | Баланың башка хокукларын бозуга карата мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.8. | Юридик мәнфәгатьләрен як-лауга мохтаҗ балаларның мөрә-җәгатьләре | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.9. | Баланы шаһит буларак җәлеп итү турында мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.10. | Юридик совет яисә мәгълүмат алу буенча мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.11. | Иректән мәхрүм итү урынна-рында җәза үтәгәннән соң, яшьләр вәкилен реабилита-цияләү турында мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4. | Яшьтәшләр белән мөнәсәбәтләр. Җенесләр арасындагы үзара | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мөнәсәбәтләр проблемалары | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.1. | Яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәтләрдә һәм аралашуда кыенлыклар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.2. | Иҗтимагый нормаларны, кыйммәтләрне кабул итмәү. Асоциаль тәртип | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.3. | Уртак булмаган мәхәббәт | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.4. | Каршы җенес белән танышудагы кыенлыклар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.5. | Җәмгыятьнең үз ориентациясен кабул итмәвенә бәйле рәвештә борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.6. | Никахлашу / никахлашу турында карар кабул итү хакында борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.7. | Хисләр суынганда, мөнәсәбәтләр өзелгәндә кичерелә торган борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.8. | Әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашуда кыенлыклар. Низаглар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.9. | Дуслар һәм иптәшләрнең булмавы | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.10. | Уку төркеме / коллегалар белән мөнәсәбәтләр турында борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.11. | Яңа әйләнә-тирәдәге кешеләргә (төркемгә/коллективка) җайлашу кыенлыклары | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.12. | Хисләр чагылышында кыенлыклар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.13. | Ирешеп булмый торган идеалга һәвәслек | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.14. | Партнерны сайлаганда кыенлыклар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.15. | Көнчелек. Хыянәт | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5. | Йөклелек. Аборт. Сексуаль өлкә | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.1. | Иртә йөклелек (13 яшьтән 17 яшькә кадәр) | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.2. | Бала туу / аборт ясау турында карар кабул итү проблемасы | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.3. | Әнинең / әтинең булачак роле белән бәйле борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.4. | Үзенең / партнерның ата-аналарының йөклелеккә карата тискәре мөнәсәбәт | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.5. | Сексуаль тәрбия (17 яшькә кадәр) бирелмәү сәбәпле, җенси мөнәсәбәтләр турында хәбәрдар-сызлык, шул исәптән контра-цепция мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.6. | Мастурбация турында борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.7. | Сексуаль ориентация турында мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.8. | Диадагы сексуаль дисгармония белән бәйле мөрәҗәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.9. | Сексуаль тәртипнең төрлелеге (күзәтүләр, фетишизм һ.б.) | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.10. | Беренче сексуаль тәҗрибәдән соң җәрәхәтләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.11. | Көчләгәннән соң җәрәхәт | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6. | Яшьләрнең физик һәм психологик сәламәтлеге | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.1. | Индивидуаль үзенчәлекләр (тышкы кыяфәтләр, физик үзенчәлекләр һ.б.) аркасында борчылулар. | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.2. | Тәмәкегә бәйлелек | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.3. | Алкогольгә бәйлелек | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.4. | Наркотикка бәйлелек | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.5. | Психик авыру яки психологик җәрәхәтләр белән бәйле борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.6. | Онкологик авырулар | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.7. | ВИЧ-инфекция, СПИД | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.8. | Интернетка бәйлелек. Уенга (компьютер һәм азарт уеннарына) бәйлелек | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.9. | Террорчылык һөҗүме яки хәрби хәрәкәтләр зонасында булу аркасында алынган җәрәхәтләр турында борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7. | Уку проблемалары һәм һөнәри юнәлеш проблемалары | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.1. | Өлгереш түбән булу һәм (яисә) белем алу турында диплом алу турында борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.2. | Уку эшчәнлегендәге кыенлыкларга, уку материалын үзләштермәүгә бәйле бочылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.3. | Белем бирү учреждениесендә укудан баш тарту, уку йортына йөрүдән баш тарту | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.4. | Укытучы белән низаг | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.5. | Һөнәрләр сайлауда / укыту эшчәнлегендә кыенлыклар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.6. | Эш эзләүдә кыенлыклар кичерү | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.7. | Һөнәри эшчәнлектәге кыенлыклар / аннан канәгатьсезлек | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.8. | Җитештерү конфликты | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8. | Социаль дезориентация һәм җайлашу проблемалары. Шәхси проблемалар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.1. | Балаларның хокук бозу очраклары (урлашу, талау, вандализм һ.б.) | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.2. | Баланың өйдән чыгып китүе | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.3. | Дискриминация (раса, милли, дини, женес, сәламәтлек торышы һ.б.) белән бәйле борчылулар. | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.4. | Күченү / миграция белән бәйле | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.5. | Мәҗбүри изоляция (төрмә, интернат, башка махсус учреждениеләр) һәм аннан соң җайлашу | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.6. | Матди кыенлыклар, начар торак шартлары | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.7. | Яшьләргә тискәре йогынты ясау белән бәйле мөрәҗәгатьләр (секталарда, экстремистик оешмаларда катнашу) | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.8. | Армиядә хезмәт итүгә бәйле рәвештә борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.9. | Тормыш юлын сайлау белән бәйле борчылулар. Үз-үзеңне тормышка ашыру проблемалары | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.10. | Экзистенциаль проблемалар (эчке кичерешләр) буенча мөрә-җәгатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.11. | Әйләнә-тирәдәге кешеләрнең өметкә туры килмәве | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.12. | Ялгызлык белән бәйле борчы-лулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.13. | Кыйммәтләрне яңадан бәяләү (18 яшьтән) | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9. | Өлешчә мобилизация белән бәйле проблемалар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.1. | Өлешчә мобилизация кысала-рында хәрби хезмәткә чакыру белән бәйле борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.2. | Өлешчә мобилизация кысала-рында чакырылган якын кеше-ләр өчен борчылулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.3. | Психик халәтнең начараюы | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.4. | Физик халәтнең начараюы | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.5. | Матди хәлнең начараюы | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.6. | Хәрби хезмәткә чакырылу теләге | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.7. | Өлешчә мобилизация турында | | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәгълүмат алу өчен мөрәҗә-гатьләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 10. | Яшьләр ышаныч телефоны хезмәте белән үзара мөнәсә-бәтләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| 10.1. | Мәгълүмат турында рәсми сорау | | | | | | | | | | | | | | | |
| 10.2. | Хезмәт өчен мәгълүмати хәбәр, ярдәм итү тәкъдиме, киңәш, дәгъва | | | | | | | | | | | | | | | |
| 10.3. | Яшьләр ышаныч телефоны хезмәте эшчәнлеге турында сораулар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 10.4. | Шалтырау-өзелү, эндәшмәү | | | | | | | | | | | | | | | |
| | Барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | |
| | Шул исәптән яшьләр ышаныч телефоны хезмәтенә беренчел мөрәҗәгатьләр саны | | | | | | | | | | | | | | | |